РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__30.01.2026 №84-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карар нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 1 февраленнән 1, 2, 3 нче кушымталар нигезендә Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә.
2. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 29 гыйнварындагы 47-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Р.Кәримов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының
_______________ № ________
карарына 3 нче кушымта

**2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе**

| № т/б | Авыл җирлекләре исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе, сум . |
|---|---|---|
| 1 | Арташ | 9 678,63 |
| 2 | Олы Кибәче | |
| 3 | Олы Нырты | |
| 4 | Олы Шыңар | |
| 5 | Югары Симет | |
| 6 | Явлаштау | |
| 7 | Эзмә | |
| 8 | Иштуган | |
| 9 | Килдебәк | |
| 10 | Курсабаш | |
| 11 | Түбән Шытсу | |
| 12 | Мишә | |
| 13 | Мичән | |
| 14 | Саба шәһәр җирлеге | |
| 15 | Сатыш | |
| 16 | Иске Икшермә | |
| 17 | Тимершык | |
| 18 | Шәмәрдән | |
| 19 | Шекше | |
| 20 | Юлбат | |

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
_______________ № ________
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында 2026 елның 1 февраленнән**
**ТАРИФЛАР**

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 355,40 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү | 967,82 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 355,40 |
| **Барлыгы** | **9 678,63** |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының
_______________ № ________
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында 2026 елның 1 февраленнән**
**ТАРИФЛАР**

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү ; | 483,95 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 3 871,45 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетне) зиратка илтү | 967,82 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 355,40 |
| **Барлыгы** | **9 678,63** |